РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

26.08.2016 — № 1082-п

Саба муниципаль районы гаиләләреннән
балаларын кайтару очракларын анализлау
буенча эксперт комиссиясе төзү турында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Опекада һәм попечительлектә торучы һәм тәрбиягә алган гаиләләрдә яшәүче балаларның хокукларын яклауны тәэмин итү турында” 2016 елның 19 маендагы 14-16 номерлы карары,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында яшәүче балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау турында” 2016 елның 26 июлендәге 1437/16 номерлы карары, “Татарстан Республикасында яшәүче гаиләләрдән балаларны кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе турында” Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 26 июлендәге 1437-16 номерлы боерыгы нигезендә тиешле комплекслы чаралар күрү, икенче ятимлекне булдырмау һәм балаларны Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларына кайтаруны булдырмау максатыннан Саба муниципаль районының башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Саба муниципаль районы гаиләләреннән балаларны кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе төзергә.

2.Саба муниципаль районында гаиләләреннән балаларны кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе турындагы нигезләмәне расларга.

3.Саба муниципаль районы гаиләләреннән балаларны кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе составын расларга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны опека һәм попечительлек бүлегенең әйдәүче белгече Г.Х. Хәлиловка йөкләргә.

Җитәкче — Р.М.Гасимов